ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КУГАРЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422662, с.Кугарчино,
ул. Советская, дом 62А

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КҮГӘРЧЕН АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕНЕҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
422662, Күгәрчен авылы,
Совет урамы, 62А йорт

Тел.: (84361) 20489, , e-mail: **Kugar.rs@tatar.ru,** сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.r

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 елның 16 октябре Күгәрчен ав. № 30

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең шәһәр төзелеше проектларының җирле нормативларын әзерләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 29.4 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының “Күгәрчен авыл җирлеге " муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең (алга таба-җирлекнең шәһәр төзелеше проектлауның җирле нормативларын) шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларын әзерләү буенча эш башкарырга.

2. Эшне башкаруның планлаштырылган нәтиҗәсе булып, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы таләпләренә туры китереп эшләнгән, җирлекнең җирле әһәмияттәге объектлар белән тәэмин ителешенең Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 23 статьясындагы 5 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән өлкәләргә караган минималь рөхсәт ителгән дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләрен үз эченә алган, авыл җирлеге халкы өчен мондый объектларның территориаль яктан мөмкин булган максималь рөхсәт ителгән дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре һәм аны килештергәндә кергән барлык искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып эшләп бетерелгән, җирлекнең шәһәр төзелеше проектларының җирле нормативлары проекты тора дип билгеләргә.

3. Билгеләргә кирәк, җирлекнең шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативлары проектын әзерләү буенча эшне башкаруның иң чик вакыты – 2017 елның 1 декабре.

4. Җирлекнең шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативлары проектын әзерләү буенча эшләрне башкару 2017 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлеге Башкарма комитетының чыгымнар сметасында каралган җирле бюджет акчалары хисабына башкарыла дип билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлеге башкарма комитетын җирлекнең шәһәр төзелеше проектлауның җирле нормативлары проектын әзерләү өчен җаваплы итеп билгеләргә (алга таба – вәкаләтле орган).

6. Җирлекне шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативлары проекты (алга таба – тәртип) буенча кызыксынучы затлар тарафыннан тәкъдимнәр бирү тәртибен расларга.

7. Вәкаләтле органга, Тәртип нигезендә, җирлекне шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативлары проекты буенча кызыксынучы затларның керә торган тәкъдимнәрен җыюны һәм гомумиләштерүне тәэмин итәргә.

8.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак – коммуналь хуҗалык бүлегенә җирлекне шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативлары проектын әзерләгәндә вәкаләтле органга тиешле ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.

9. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авылы, Совет урамы, 62А йорт; Зәңгәр-Күл авылы, Тукай урамы, 3А йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya- sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат- телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

10.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күгәрчен авыл
җирлегеБашкарма
комитетының 2017 елның
16 октябрендәге
30 номерлы карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең шәһәр төзелеше проектларының җирле нормативлары проекты буенча кызыксынган затлар тарафыннан тәкъдимнәр бирү тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең шәһәр төзелеше проектларының җирле нормативлары проекты буенча кызыксынган затларның тәкъдимнәре Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлеге башкарма комитетына язмача рәвештә, үрнәк буенча төзәтмәләр таблицасы рәвешендә, язмача рәвештә кертелә:

| № п/п | Пункт, подпункт | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең шәһәр төзелеше проектының җирле нормативлары проекты тексты | Төзәтмәләр тексты | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авылҗирлегенең шәһәртөзелеше проектының җирле нормативлары проекты тексты, төзәтмәне исәпкә алып, | Төзәтмә авторы (Ф. И.О., адрес, телефон, эшурыны (уку) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

2. Кызыксынган затларның тәкъдимнәре түбәндәге адрес буенча җибәрелә: 422662, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Күгәрчен авылы, Совет урамы, 62А йорт, яки (88-43-61)20-489.

Кызыксынган затларның тәкъдимнәреэ шкөннәрендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең шәһәр төзелеше проектының җирле нормативлары проекты урнаштырылган көннән алып ике ай эчендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципальрайонының Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәгерәсмисайтында веб-адрес буенча кабул ителә: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге«Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Кызыксынган затларның тәкъдимнәре Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлеге башкарма комитеты хезмәткәрләре тарафыннан теркәлә һәм карау өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлеге Башкарма комитетының җаваплы вазыйфаи затларына тапшырыла.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күгәрчен авыл җирлеге башлыгы А.Т.Сафин